Зарегистрировано в Управлении
Министерства юстиции
Российской Федерации
по Республике Татарстан
14 июня 2023 года
Государственный регистрационный
номер RU 165300002023001

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ — КАРАР

№ 34 — 2023 елның 29 мае

## Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап чыкканнан соң, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2014 елның 18 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Түбән Кама муниципаль районы Башлыгына әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы — Р.Х. Муллин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2023 елның 29 маендагы
34 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясында:

а) 1 өлешнең 36 пунктында «, ясалма җир участогы булдыру турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.».

2. «Район составына керүче авыл җирлекләре территориясендә районның җирле үзидарә органнары хәл итә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр» 6.1 статьясында 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район составына керүче авыл җирлекләре (алга таба - авыл җирлекләре) территориясендә районның җирле үзидарә органнары хәл итә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә түбәндәгеләр керә:

1) авыл җирлекләре чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ белән тәэмин итүне оештыру;

2) бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле һәм аның өчен «Җылылык белән тәэмин итү турында» федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча чараларны үтәвенә җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

3) авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларын файдалану һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

4) авыл җирлекләрендә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ азкеремле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

5) халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм авыл җирлекләре чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

6) терроризм һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук авыл җирлекләре чикләрендә терроризм һәм экстремизм күренешләренең нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу;

7) авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен кисәтүдә һәм бетерүдә катнашу;

8) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, авыл җирлекләре китапханәләренең китапханә фондларын тулыландыру һәм саклауны тәэмин итү;

9) авыл җирлекләре милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклау, куллану һәм популярлаштыру, авыл җирлекләре территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклау;

10) җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, авыл җирлекләрендә халык сәнгать һөнәрләрен саклауда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

11) авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарын, аеруча саклана торган табигый территорияләр урманнарын файдалану, саклау, яклау, яңадан үрчетүне оештыру;

12) авыл җирлекләренең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәт бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), авыл җирлекләре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү, авыл җирлекләрен шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен авыл җирлекләре чикләрендә җир кишәрлекләрен тартып алу, авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирүне гамәлгә ашыру, индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын планлаштырылган төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының (алга таба - планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамә) билгеләнгән параметрларга һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруны рөхсәт итү турында хәбәрнамәгә туры килүе турында хәбәрнамә юллау, индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының планлаштырылган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, төзелгән яки реконструкцияләнгән индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында хәбәрнамә, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар, үз белдеге белән төзелгән бинаны сүтү яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру;

13) авыл җирлекләре торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларны, алар составында төзелә торган участок урманчылыкларын булдыру, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук авыл җирлекләре торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауны гамәлгә ашыру;

14) авыл җирлекләре торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын гамәлгә ашыру;

15) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, халыкны һәм авыл җирлекләре территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру;

16) авыл җирлекләре территориясендә авария-коткару хезмәтләрен һәм (яки) авария-коткару формированиеләрен булдыру, карап тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

17) авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру;

18) авыл җирлекләре территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге аеруча саклана торган табигый территорияләрне файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

19) Россия Федерациясе су законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары хуҗасының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, халыкны аларны куллануны чикләү турында мәгълүмат бирү;

20) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

21) авыл җирлекләрендә хезмәт күрсәтелә торган административ участокларда эшләү өчен участокның вәкаләтле полиция хезмәткәре вазыйфасын биләүче хезмәткәрләргә урын бирү;

22) «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 31.1 һәм 31.3 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү;

23) авыл җирлекләре ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрнең үтәлешен тәэмин итү, федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү;

24) авыл җирлекләре чикләрендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру;

25) «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу;

26) карарлар кабул итү һәм авыл җирлеге территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар үткәрү, әлеге күчемсез милек объектларының хокук ияләре турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрү.».

3. «Гавами тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышулар» 16 статьясында 3.1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында муниципаль хокукый актлар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында муниципаль хокукый актлар проектлары, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен, җирдән файдалану һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда, мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарга ярашлы рәвештә гавами тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрелә.»

4. «Район Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат статусы» 27 статьясында:

а) 4.3 өлеше үз көчен югалткан дип танырга;

б) 7 өлешнең 2 нче пунктында:

- «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга,

«б» пунктчасында:

«муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга.

5. «Район Советы компетенциясе» 30 статьясының 1 өлешендәге 15 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

6. «Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 36 статьясының 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 12.1 пункт белән тулыландырырга:

«12.1) район Советының барлык утырышларында алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез депутат булмау;»;

б) 14 пунктны төшереп калдырырга.

7. «Район Башлыгы - районның югары вазыйфаи заты» 37 статьясының 2 өлешендә «район Советы» сүзләреннән соң «үз составыннан» сүзләре белән тулыландырырга.

8. «Район Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 41 статьясында:

а) 1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт белән тулыландырырга:

«4.1) «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25 статьясындагы 13 пунктына ярашлы рәвештә вазыйфадан баш тарту;»;

б) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга.

9. «Башкарма комитетның вәкаләтләре» 45 статьясындагы 2 пунктының 2.7 пунктчасында «ясалма җир кишәрлеге булдыру турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. «Район Башкарма комитеты җитәкчесе» 46 статьясында:

а) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләре белән алыштырырга.

б) 9 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләре белән алыштырырга.

в) 10 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга.

11. «Район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү тәртибе» 47 статьясындагы 7 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга.

12. «Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 50 статьясында:

а) 1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт белән тулыландырырга:

«4.1) «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25 статьясындагы 13 пунктына ярашлы рәвештә вазыйфадан баш тарту;»;

б) 2 өлешнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

в) 2.1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга.

13. «Район бюджет һәм финанслар департаменты» 54 статьясында 3 өлешне түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Район бюджет һәм финанслар департаменты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында башкарыла. Күрсәтелгән тикшерүне үткәрүдә Татарстан Республикасы финанс органының катнашу тәртибе «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта белән билгеләнә.».

14. «Сайлау комиссиясе» VIII бүлеген үз көчен югалткан дип танырга.

15. «Район Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре» 62 статьясында 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

16. «Муниципаль норматив хокукый актлар белән эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләрнең, инвестицион эшчәнлек субъектлары өчен бурычларның яңаларын билгели торган яки элек каралганнарын үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайлау йогынтысын бәяләү» 72.1 статьясында 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль норматив хокукый акт проектының җайлау йогынтысын бәяләү нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы (җирле үзидарә органы вазыйфаи заты) тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проектында эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертүче яисә аларны кертүгә ярдәм итүче нигезләмәләр, шулай ук эшмәкәрлек һәм башка икътисади эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итүче нигезләмәләр булуы (булмавы) турында нәтиҗәләр булган бәяләмә әзерләнә.».

17. «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе» 76 статьясында 9 өлештә:

а) беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

«, һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru)»;

б) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтын (http://www.e-nkama.ru) кулланырга хокуклы. «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) һәм/яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru) муниципаль хокукый актның тулы тексты бастырылган (урнаштырылган) очракта, күләмле график һәм таблицалы кушымталар матбугат басмасында китерелмәскә мөмкин.».

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.Х. Муллин